| ГЛАВА ВОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВОЙКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Базяково ав.

30.10.2019 № 5

**Алексеевского муниципаль районының**
**“Базяково җирлеге территориясендәге**
**Базяково авылында үзара салым кертү**
**һәм гражданнарның үзара салым**
**акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын билгеләү турында “**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы» , Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Базяково җирлеге территориясендәге Базяково авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 11 нче ноябре көнне 11сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Алексеевск муниципаль районы Войкино җирлеге территориясендәге Войкино авылында 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар ,1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- торак пунктлардагы урамнарны төзекләндерү һәм карап тоту;
- Войкино авылында чишмәне төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;

“ ӘЙЕ " КАРШЫ”

3.Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Җыенны уздыру урыны итеп Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Базяково авылы, Федин урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасын билгеләргә. Әлеге карарны Войкино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Базяково авылы, Федин урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Войкино авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Н.П.Шабутдинова**